СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
Арского муниципального района
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦПИАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк
авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

## Үрнәк авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**от « 10 » октября 2019г.** **№ 51**

### Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

Референдум уздыру турында «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.04.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

" 2020 елда Үрнәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләүләр күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге уку формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| №п/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | . Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | Үрнәк авылында: Наратлы урамы – 1-5а йорт, Тау асты ур., 5-10 йорт, Күпер ур.,11 йорт, Урман ур., 11 йорт; Түбән Пошалым авылы Пионер ур.,1-9 йорт; Югары Пошалым авылы Мичурин ур., 8-18 йорт, Урал ур., 1-6 йорт; Урта Пошалым авылы Сәйдәшев ур., 1-10 |

| | | |
|---|---|---|
| | | йорт; Көтек авылы Комсомол ур., 20-23 йорт, Мәктәп ур., 60-66 йорт; Казанбаш авылы Җиңү ур., 27-33 йорт, Киров ур., 1-36 йорт, Мәктәп ур., 96-105 йорт, Яшьләр ур., 126-134 йорт; Дүртөйле авылы Күпер ур., 1-5 йорт; Апайкина Гарь авылы Үзәк ур., 20-32 йорт; Казанка авылы Җиңү ур., 10-15 йорт; Күлтәс авылы Р. Мөбәрәкшин ур., 25-30 йорт, Г. Кәбиров ур., 10-15 йорт, Бертуган Зыятдиновлар ур., 21-25 йорт; Гарталовка авылы Урман урамы ур., 20-25 йорт; Иске Төрнәле авылы Комсомол ур., 58-61 йорт; |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | Үрнәк, Алга – Көек, Казанка авылларында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычларны, лампалар, үз-үзен изоляцияләгән үткәргечләрне, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, бушаткычлар сатып алу һәм урнаштыру;<br>Алга -Көек, Апайкина Гарь, Кече Төрнәле авыллары янында рөхсәтсез чүплекләр урнаштырылган урыннардагы җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;<br>Кече Төрнәле, Көтек, Үрнәк (ике чишмә), Казанбаш, Алга -Көек, Тылангыр авылларында чишмә территориясенә материаллар сатып алу, ремонтлау һәм төзекләндерү. |
| 3 | Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм күмү урыннарын булдыру | Югары Пошалым, Бимәр, Үрнәк, Тылангыр авылларында зират коймасын сатып алу һәм ремонтлау;<br>- Күлтәс авылында зиратны чиста һәм тәртиптә тоту өчен чүп-чар җыю контейнеры, бензокос, чылбыр сатып алу;<br>- Күлтәс, Иске Төрнәле авылларында зират эчендәге агачларны кисү. |

ӘЙЕ ЮК"

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http:pravo.tatarstan.ru гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адрес буенча мәгълүмати стендларда: Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк авылы, Урман урамы, 44А йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы И.Р. Камалетдинов